ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**4 марта 2016 г.**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 03-03-499**

Зеленодольск шәһәре, Кояшлы урамы, 6 йорт адресы буенча урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын һәм җир участогын тартып алу турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 26 сентябрендәге 2178 карары белән расланган 2013-2017 елларга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программаны тормышка ашыру максатыннан, 2007 елның 21 июлендәге 185 номерлы «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» Федераль законы, Россия Федерациясе Торак, Җир кодекслары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре, Кояшлы урамы, 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы Кояшлы урамындагы 6 номерлы торак йорттагы җир участогын, шулай ук әлеге йортта урнашкан исемлек (кушымта) буенча күчемсез мөлкәт объектларын (торак һәм торак булмаган биналарны) муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен җибәрергә:

- тартып алына торган күчемсез мөлкәтнең хокук ияләре;
- күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәлүен башкаручы органга;
- "Торак сәясәте Департаменты" МКУ

4. «Зеленодольск муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир участогының урнашу схемасын раслауны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Сәхибуллин